ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**"Казан (Идел буе) федераль университеты" федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесендә белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Татарстан Республикасы территориясендә фәнни-тикшеренү һәм инновация эшчәнлеген камил, тотрыклы һәм нисбәтле үстерүгә ярдәм итү; икътисадның төрле тармакларында һәм социаль өлкәдә гамәли әһәмияткә ия яңа фәнни мәктәпләр булдыру нигезендә Татарстан Республикасында заманча мәгариф системасын төзү; Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенә Россиянең һәм чит илләрнең әйдәп баручы фән-мәгариф үзәкләренең һәм корпорацияләренең алдынгы тәҗрибәсен кертү; Татарстан Республикасын социаль-икътисадый һәм социаль-мәдәни үстерү өлкәсендә программалар һәм проектлар эшләү һәм аларны фәнни яктан тәэмин итү максатларында, әлеге Законда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) "Казан (Идел буе) федераль университеты" федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесендә (алга таба – Университет) белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре;

2) Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Университетның үзара эшчәнлегенең төп юнәлешләре.

2 статья. **Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүнең хокукый нигезе**

Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүнең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Төньяк-Көнбатыш, Идел буе, Урал һәм Ерак Көнчыгыш федераль округларында федераль университетлар төзү турында" Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 октябрендәге 1172 номерлы Указы, Россия Федерациясенең бүтән норматив

хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, "Мәгариф турында" 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 13 сентябрендәге 1543-р номерлы күрсәтмәсе белән хупланган 2010 – 2019 елларга "Казан (Идел буе) федераль университеты" федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесен үстерү программасы, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары тәшкил итә.

3 статья. **Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәмен, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, экологик, демографик, этномәдәни һәм башка региональ үзенчәлекләрен исәпкә алып, Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын законнарда билгеләнгән тәртиптә эшләү һәм тормышка ашыру юлы белән Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы законнары кабул итү, аларның үтәлешен Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм рәвешләрдә тикшереп тору;

2) Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджеты составында раслау;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Университетка түләүсез куллануга тапшыру турында карарлар кабул итү;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын үз компетенциясе чикләрендә эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча вәкаләтләрен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә гамәлгә ашыра.

4 статья. **Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасы**

Татарстан Республикасы дәүләт программасы Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган программалар һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актлары кысаларында Университетны үстерүнең төп юнәлешләре нигезендә Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын билгели.

5 статья. **Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Университетның үзара эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Университетның үзара эшчәнлеге түбәндәге төп юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

1) белем бирү процессын белем бирүнең яңа төрләрен, программаларын һәм стандартларын эшләү, белем бирүнең яңа технологияләрен һәм уку-укытуга ярдәм итү системаларын кертү юлы белән модернизацияләү;

2) фәнни-тикшеренү процессын модернизацияләү;

3) Университетның кадрлар потенциалын үстерү, шул исәптән фәнни-педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсешенә ярдәм итү һәм аны стимуллаштыру, кадрларны яңарту, Россия һәм чит илләр укытучыларын, тикшеренүчеләрен һәм практикларын җәлеп итү;

4) Университет инфраструктурасын модернизацияләү;

5) Университетны глобаль фәнни-мәгариф һәм инновация челтәрләренә тоташтыру һәм төбәк дәрәҗәсендә аларның формалашуына ярдәм итү;

6) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре кысаларында башка юнәлешләр.

6 статья. **Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәмен финанс белән тәэмин итү**

1. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелә торган

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләме Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

7 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 9 июне
№ 48-ТРЗ